ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2020 Балык Бистәсе штп. №243пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләү турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 маддәләре, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 маддәләре, “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 2010 елның 25 октябрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 15 пункты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.

2. Проектны эшләү срогын билгеләргә: 31.01.2021.

3. Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетына проектның тәртибе, әзерләү сроклары һәм эчтәлеге турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л.Исланов